МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

05.11.2020 Казан ш. № 3401-р

**Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 30.12.2013 № 4083-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән документациягә туры китереп, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Актаныш, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Мөслим, Питрәч, Сарман, Тәтеш муниципаль районнары территорияләрендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында” 30.12.2013 № 4083-р карары (алга таба - № 4083-р Карар) белән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясенә урнаштырылган 30213 инвентарь номерлы бүлгеч газүткәргечнең 16:33:080514:129, 16:33:080514:128, 16:33:000000:3442 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге саклау зонасы чикләрен үзгәртергә.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән һәм өлешчә яки тулысынча күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зонасына туры килгән җир

кишәрлекләренә 30213 инвентарь номерлы газүткәргеч өлешләренең эксплуатация срогында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Кадастр недвижимости» ҖЧҖ әзерләгән Территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, җир асты газүткәргече чикләренең характерлы ноткалары координаталары исемлеге нигезендә № 4083-р карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Питрәч муниципаль районы территориясендә урнаштырылган 465,165 км озынлыктагы, әлеге карарның 9 нчы кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү газүткәргеченең «Кадастровый центр «Граница» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ таарфыннан 2013 елның 20 ноябрендә килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектоларның саклау зонасы картасы (планы) нигезендә.»;

9 нчы кушымтада 30213 инвентарь номерлы газүткәргеченә туры килә торган юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 30213 | | ТР, Питрәч районы, Кощакова, Богородское авыл җирлекләре | 15059,833 | d=160,<br>d=110,<br>d=63<br>Урта басым | 16:33-2.2001-529.1<br>01.10.2001 |

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**